ГЛАВА САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.05.2023 с. Сарманово № 79

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2021 елның 12 февралендәге УП-132 номерлы Указы нигезендә карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында кушымтада бирелгән Нигезләмәне расларга.
2. Сарман муниципаль районы башлыгының 2014 елның 23 маендагы 70 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Сарман муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Ю.Р. Исмәгыйлевага йөкләргә.

Сарман муниципаль районы

Башлыгы Ф.М.Хөснуллин

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
башлыгы карарына кушымта
22.05.2023 № 79

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ РЕЕСТРЫН АЛЫП БАРУ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре реестрының эчтәлеген һәм аны алып бару тәртибен билгели.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре реестрлары Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының муниципаль хезмәт (алга таба - муниципаль хезмәт) вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләренең (алга таба - муниципаль хезмәткәрләр) белешмәләре нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының җирле үзидарә органнарында (алга таба- җирле үзидарә органнары) төзелә.

3. Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре реестрын (алга таба - муниципаль хезмәткәрләр реестры) төзиләр, ул җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр турында белешмәләрнең җыелма исемлеген тәшкил итә.

4. Муниципаль хезмәткәрләр реестрына кертелгән белешмәләр федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләргә, ә башка очракларда - конфиденциаль характердагы белешмәләргә карый һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә якланырга тиеш.

5. Муниципаль хезмәткәрләр реестры "Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм мәгълүмати системасы" дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба - Мәгълүмати система) алып барыла, анда булган мәгълүматны санкцияләнмәгән файдалану, юкка чыгару, үзгәртү, блоклау, күчереп язу, тарату, шулай ук башка хокуксыз гамәлләрдән яклауны тәэмин итеп алып барыла.

## II. Муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару

6. Муниципаль хезмәткәрләр реестры Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хезмәтен мәгълүмати системада кадрлар белән тәэмин итү секторы тарафыннан алып барыла.

7. Муниципаль хезмәткәрләр реестрын төзү һәм алып бару Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хезмәтен Мәгълүмат системасында җирле үзидарә органнарында тапшырылган муниципаль хезмәткәрләр реестрлары нигезендә кадрлар белән тәэмин итү секторы тарафыннан гамәлгә ашырыла. Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хезмәтне кадрлар белән тәэмин итү секторы муниципаль хезмәткәрләрнең төзелгән Реестрын Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына (алга таба - Департамент) агымдагы елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча җибәрә.

8. Муниципаль хезмәткәрләр реестрының рәвешләре Дәүләт органында һәм Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләре реестрының Департамент тарафыннан расланган рәвешләренә туры килә һәм мәгълүмат системасында урнаштырыла.

9. Муниципаль хезмәткәрләр реестрына муниципаль

хезмәткәрнең шәхси белешмәләре турында белешмәләр керә;

муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәт үтүче җирле үзидарә органы исеме;

әлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе исемнәре;

Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры нигезендә муниципаль хезмәткәр биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы исеме;

муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттәге кадрлар резервына кертү (кадрлар резервына кертү датасы, вазыйфаның исеме, кадрлар резервына кертү өчен нигез, кадрлар резервыннан төшереп калдыру өчен нигез).

10. Муниципаль хезмәткәрнең шәхси белешмәләре түбәндәгеләрне үз эченә ала:

муниципаль хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган

очракта) турында; туу датасы турында;

һөнәри белем турында (белем бирү оешмасының исеме, дипломның номеры һәм датасы, белгечлек һәм квалификация);

хәрби хезмәт узу турында;

һөнәри яңадан әзерлек узу турында (белем бирү оешмасы исеме, уку тәмамлану датасы, программаның исеме, нәтиҗәдәге документның төре һәм номеры);

квалификация күтәрү турында (белем бирү оешмасының исеме, уку тәмамлану датасы, программаның исеме, нәтиҗәдәге документның төре һәм номеры);

гыйльми дәрәҗә турында (гыйльми дәрәҗә исеме, бирү датасы);
гыйльми исем турында (гыйльми исеме, бирү датасы);
елларда, айларда, көннәрдә исәпләнгән гомуми хезмәт стажы турында;
елларда, айларда, көннәрдә исәпләнгән муниципаль хезмәтнең стажы турында;

аттестация узу турында (аттестация үткәрү датасы, аттестация комиссиясе карары);

класс чины турында (класс чины, аны бирү турында актның датасы һәм номеры);

дәүләт бүләкләре һәм башка бүләкләр турында (бүләк төре, бүләкләү датасы);

муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс узу турында (әгәр граждан конкурс нәтиҗәләре буенча вазыйфасына билгеләнсә);

хезмәт шартнамәсе турында (контракт - башкарма комитет җитәкчесе өчен) хезмәт шартнамәсенең (контракт - башкарма комитет җитәкчесе өчен ) төзү датасы, аның гамәлдә булу срогы, аңа үзгәрешләр кертү датасы).

Муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси мәгълүматларының әлеге исемлеге төгәл булып тора һәм муниципаль хезмәткәрләр реестрына карата гына кулланыла.

11. Муниципаль хезмәткә керә торган гражданнар турында белешмәләр җирле үзидарә органнары җитәкчеләре (муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар) актлары нигезендә муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгән көннән алып ике эш көне эчендә җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрына кертелә.

12. Муниципаль хезмәткәрне шул ук җирле үзидарә органында башка вазыйфага билгеләгәндә аны муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләү турындагы белешмәләр муниципаль хезмәткәрләр реестрына җирле үзидарә органы җитәкчесе (муниципаль вазыйфаны биләүче зат) тарафыннан билгеләнгән көннән алып ике эш көне эчендә җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнү турындагы акт нигезендә кертелә.

13. Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан муниципаль хезмәткәр турындагы белешмәләрне төшереп калдыру өчен аны эштән азат итү, муниципаль вазыйфага яисә муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнү, үлем (һәлак булу), шулай ук затны хәбәрсез югалган дип тану яисә аны законлы көченә кергән суд карары белән үлгән дип тану нигез була.

Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан муниципаль хезмәткәр турындагы белешмәләрне төшереп калдыру өчен аны шулай ук муниципаль хезмәт вазыйфасына башка җирле үзидарә органында билгеләп кую нигез булып тора.

Муниципаль хезмәткәр турында белешмәләр җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан эштән азат ителү, башка җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнү, муниципаль хезмәт вазыйфасы булмаган муниципаль вазыйфага билгеләнү, үлем (һәлак булу) яки судның тиешле карары законлы көченә кергән көнне чыгарыла.

14. Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрында тиешле үзгәрешләр турындагы белешмәләр ике эш көне эчендә Сарман муниципаль районы башкарма комитетының муниципаль хезмәтен кадрлар белән тәэмин итү секторы тарафыннан Департаментка җибәрелә.

15. Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт узган һәм җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан чыгарылган муниципаль хезмәткәрләр турындагы белешмәләр кануннар нигезендә архивка тапшырыла.

16. Муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару белән бәйле бәхәсләр закон нигезендә хезмәт бәхәсләре буенча комиссияләр һәм суд тарафыннан карала.

## III. Муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып баруны тикшереп тору

17. Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып баруны контрольдә тотуны җирле үзидарә органы җитәкчесе (муниципаль вазифаны биләүче зат) тәэмин итә. Контроль шәхси эшләрнең булу-булмавын һәм аларның торышын тикшерү, муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси мәгълүматларын үз эченә алган мәгълүматларны җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрләр реестрындагы мәгълүматлар белән чагыштыру рәвешендә башкарыла.

Белешмәләрне тикшерү факты тиешле актта чагыла.

18. Муниципаль хезмәткәрләр реестрын формалаштыру һәм алып бару бурычлары йөкләнгән муниципаль хезмәткәрләр, закон нигезендә, конфиденциаль характердагы мәгълүматларны һәм дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларны ачу өчен җаваплы.

## IV. Муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан белешмәләр тапшыру һәм реестрны саклау

19. Муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан белешмәләр Сарман муниципаль районы башкарма комитетының муниципаль хезмәтен кадрлар белән тәэмин итү секторы тарафыннан Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы башлыгына тапшырыла.

20. Муниципаль хезмәткәрләр реестры, аңа үзгәрешләр мәгълүмат системасында саклана, аларда булган мәгълүматны рөхсәтсез керүдән, юк итүдән, үзгәртүдән, блоклаудан, күчереп язудан, таратудан, шулай ук башка законсыз гамәлләрдән яклауны тәэмин итә.